ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**25.02.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 398**

Аерым муниципаль хокукый актларның үз көчләрен югалтуын тану турында

2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 248-ФЗ номерлы Федераль закон нормалары һәм таләпләре гамәлгә керүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Үз көчләрен югалтуын танырга:

1.1. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 мартындагы 626 номерлы карары.

1.2. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 мартындагы 626 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 07 маендагы 1025 номерлы карары.

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев